РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**исполнительный комитет**
**Большесалтыковского сельского поселения**
422831, Республика Татарстан,
Камско-Устьинский район,
с. Б.Салтыки, ул.1 Мая, 26А
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы**
**муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл жирлеге**
**башкарма комитеты**
422831, Татарстан Республикасы,
Кама Тамагы районы,
Олы Салтык авылы, 1 Май урамы, 26А
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«11» июль 2025 ел** **№16**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 сентябрендәге 831 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 25 декабрендәге 1516 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге башкарма комитеты 2020 елның 31 мартындагы 12 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең

салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлектә:

**12 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:**

«12. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатка ярашлылыгы критерийлары булып тора:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программаларга карамаган муниципаль программалар максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

Ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының биш ел эчендә нисбәте белән характерлана торган ташламаларга түләүчеләр тарафыннан ихтыяҗ булу.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары кураторлары кирәк булганда, түләүчеләр өчен ташламалар бирүнең максатка ярашлы башка критерийлары билгеләнергә мөмкин.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗын бәяләүне уздыру максатларында ташламалар таләп ителгән әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән нисбәтнең минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин, бу чакта ташлама кирәкле дип таныла.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә туры килмәгән очракта, муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары кураторына, түләүчеләр өчен ташламаларны саклап калу (төгәлләштерү, бетерү) турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык  авыл җирлеге башкарма комитетына тапшырырга кирәк.»;

**түбәндәге эчтәлекле 15.1 пункт өстәргә:**

«15.1.Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары кураторы кирәк булганда, муниципаль берәмлек салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүнең өстәмә критерийлары билгеләнергә мөмкин.»;

**түбәндәге эчтәлекле 16.1 пункт өстәргә:**

«16.1.Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне муниципаль берәмлекнең техника салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рөхсәт ителә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Вафин